РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

24 июля 2018 г. № 170

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы Федераль законның 44 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставының 85, 86, 87 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы КАРАР чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы №191 санлы карары белән 2010 нчы елның 07 августында кабул ителгән (Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карары белән №118 санлы 2012 нче елның 8 октябрендә, №214 санлы 2014 нче елның 29 апрелендә, №278 санлы 2015 нче елның 8 апрелендә, №26 санлы 2016 нчы елның 21 гыйнварында, №65 санлы 2016 нчы елның 19 декабрендә, №94 санлы 2017 нче елның 22 маенда, №125 санлы 2017 елның 13 декабрендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 нчы статья:

1 нче өлештә:

а) 5 нче пунктта түбәндәге сүзләрдән соң: “район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын саклап калу өчен” “юл хәрәкәтен оештыру”дигән сүзләр өстәргә;

б) 16 нчы пунктны түбәндәгечә бәян итәргә: “район территориясендә каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән, аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу”;

в) 31 нче пункт “(волонтерлыкка)” дигән сүзне өстәргә;

г) 39 нчы пункттан “муниципаль районның авыллар арасындагы территориясе чикләрендә планлаштыру структурасы исеме” дигән сүзләрне чыгарырга;

д) түбәндәге 41 нче пунктны өстәргә: “стратегик планлаштыру өлкәсендә "Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган вәкаләтләр”.

е) 2 нче өлешне үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. 7 нче статья:

- 1 нче өлешнең 7 нче подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә: «федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар кабул итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру”.

1.3. 10 нчы статья:

- 13 нче пунктны түбәндәгечә бәян итәргә: “иҗтимагый фикер алышу”;

- 13 нче пунктны 14 пункт итеп санарга.

1.4. 16 нчы статья:

- 16 нчы статьяның исемен яңа редакциядә бәян итәргә: “16 нчы статья. Халык тыңлаулары, иҗтимагый фикер алышу”;

- 1 нче өлештә “халык тыңлаулары” сүзтезмәсен “яки иҗтимагый фикер алышу” белән тулыландырырга;

- 3 нче өлешнең 3 һәм 5 подпунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

- 1 нче өлешнең 4 подпунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «районны үзгәртеп кору турында сораулар, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә Районны үзгәртү өчен тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында белдерелгән район халкының ризалыгы алу таләп ителгән очраклардан тыш”;

- түбәндәге эчтәлектәге 3.1. өлеше белән тулыландырырга: «генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектлар, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш объектларының чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектлары, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалану рөхсәт ителгән бер төрне үзгәртү мәсьәләләре

буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда, мондый кулланунын башка төре җәмәгать тикшерүләре яисә халык тыңлаулары үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе нигезләмәләрне исәпкә алып, район Советы Уставы һәм норматив хокукый акты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә;

- 5 нче өлешне түбәндәгечә бәян итәргә: "Җәмәгать фикер алышуларын, халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе, җәмәгать фикер алышуларын, халык тыңлауларын бастырып чыгару (халыкка игълан итү) тәртибе район Советы тарафыннан расланган Нигезләмә белән билгеләнә".

1.5. 30 нчы статья:

- 1 нче өлештә 5 нче пунктны чыгарырга;

- 5.1. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: 2 муниципаль районның стратегик планлаштыру документларын карау, раслау (хуплау)";

- 1 нче өлешне түбәндәге эчтәлектәге 32 нче подпункт белән тулыландырырга: "32) муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау";

- 32 нче подпунктны 33 нче подпункт итеп санарга.

1.6. 34 нче статьяны яңа редакциядә бәян итәргә: "1. Район Советының вәкаләтләре вакытыннан алда киләсе очракларда туктатылырга мөмкин:

- район Советы үз-үзен таркату турында карар кабул иткән очракта. Шул ук вакытта үз-үзен таркату турындагы карар әлеге Устав белән билгеләнгән тәртиптә кабул ителә;

- район Советы депутатларының әлеге составының хокуксыз булуы турында Татарстан Республикасы Югары суды карары үз көченә кергән очракта, шул исәптән депутатлар үз вәкаләтләрен туктатуга бәйле рәвештә;

- районны районны №131-ФЗ санлы Федераль законның 13 статьясындагы 4,6 өлешләре нигезендә үзгәртеп корган очракта, шулай ук район бетерелгән очракта;

- район чикләрен үзгәртү нәтиҗәсендә район сайлаучылары саны 25 проценттан арткан очракта;

- гражданнарның турыдан-туры белдерүләре юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны бастырып чыгару вакыты бозылган очракта.

2. Район Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату аның депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатуга китерә.

3. Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта җирлекләрнең вәкиллекле органнары бер ай эчендә район Советына башка депутатларны сайларга тиеш".

1.7. 41 нче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 2.1. өлеше белән тулыландырырга:

"2.1. Әгәр Татарстан Республикасы Президентының Район Башлыгын вазыйфасыннан читләштерү турында хокукый акты нигезендә йә Район Башлыгының отставкага китүе турында район Советы карары нигезендә Район Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган булып, Район Башлыгы әлеге хокукый актка яисә карарга суд тәртибендә шикаять бирсә, муниципаль сайлауларда сайланучы Район Башлыгын вакытыннан алда сайлауларына кадәр суд карары үз көченә кергәнче билгеләнә алмый".

1.8. 45 нче статьяда:

а) 1 нче өлештә 6 нчы абзацны чыгарырга;

б) 7 нче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

“1) район социаль-икътисадый үсешенең һәм мунципаль идарәсенең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең өстенлекләре һәм максатлары килешенгән озак вакытка исәпләнгән максатларын һәм бурычларын билгели;

2) җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын әзерли, карый, раслый (хуплый) һәм тормышка ашыра;

3) район Советы тарафыннан расланган стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

4) федераль законнар һәм муниципаль норматив-хокукый актлар белән билгеләнгән стратегик планлаштыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра”;

в) 10 нчы абзацта “законда билгеләнгән” сүзтезмәсен “Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән” дип бәян итәргә;

г) 3 нче өлештә 4 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:” район территориясендә каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән, аерым җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша”;

- 2 нче өлешнең 9 нчы пукнтының 11 нче подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә: «федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыра, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларының сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар кабул итүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыра”.

1.9. 72 нче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 7 нче өлеш белән тулыландырырга: “Муниципаль вазыйфа биләгән затка карата коррупциячел хокук бозулар кылган өчен ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү (вазыйфасыннан азат итү) рәвешендәге түләтү турында белешмәләр бу зат анда тиешле вазыйфа биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 278-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә”.

1.10. 80 нче статьяның 7 нче пунктының 4 нче абзацын көчен югалткан дип санарга.

1.11. 82 нче статьяны яңа редакциядә бәян итәргә:

“1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салым түләүләре күләме муниципаль берәмлекнең барлык халкы өчен дә тигез күләмдә билгеләнә, аларның саны муниципаль берәмлек халкының гомуми санынннан 30 проценттан артып китә алмый һәм алар өчен түләү күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш.

2. Әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән гражданнар бер тапкыр түләргә тиешле түләүләрне кертү һәм куллану турындагы мәсьәлә җирле референдумда (гражданнар җыенында) хәл ителә.

1.12. 87 нче статьяны түбәндәге эчтәлектәге 4 нче өлеш белән тулыландырырга:

“Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү муниципаль хокукый акт тарафыннан кертелә, аны түбәндәгечә рәсмиләштереп була:

- Район Советы (гражданнар җыены) рәисе һәм Район Башлыгы имзалаган, яисә Район Советы (гражданнар җыены) рәисе вәкаләтләрен башкаручы Район Башлыгы имзалаган район Советы (гражданнар җыены) карары нигезендә;

- Район Советы (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм Район Башлыгы имзалаган аерым норматив хокукый акт нигезендә. Бу очракта әлеге хокукый актта район Советының (гражданнар җыенының) аны кабул итү турындагы карары реквизитлары куела. Район Советының (гражданнар җыенының) мондый карарына күчеш нигеләмәләре һәм (яисә) район Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турындагы нормалар кертү рөхсәт ителми.

2. Әлеге карарның 1.1. пунктының “б” подпункты, 1.8. пунктының “г” подпункты дәүләт теркәвенә алынганнан соң үз көченә керә, ләкин 2019 нчы елның 1 нче гыйнварыннан да иртәрәк түгел дип билгеләргә.

3. Әлеге караны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Әлеге карар дәүләт теркәвен узганнан соң Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге карар 2003 нче елның 6 октябреннән №131-ФЗ санлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 статьясының 8 нче өлешендә каралган нигезләмәләргә, "Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставының 87 нче статьясының 2 нче өлешенә нигезләнеп аны рәсми игълан иткән көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарны контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Муниципаль район Совет рәисе,
район башлыгы Ф.М. Дәүләтшин